ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.02.2022 Олы Кайбыч ав. № 75

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын кушымтада бирелгәнчә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.
2. 4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 е. “17” февралендәге
75 номерлы карарына кушымта

**Форма**

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)**

*( Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 е. ____________________ __ номерлы карары белән расланган)*

1. Әлеге тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда планлы тикшерүләр уздырганда кулланыла.

2. Планлы тикшерү предметы әлеге тикшерү кәгазенә (контроль сорауларга) кертелгән мәҗбүри таләпләрне үтәү белән чикләнә.

3. Аңа карата планлы тикшерү уздырыла торган юридик затның исеме, шәхси эшкуарның, ИНН, ОГРН/ОГРНИП, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта): ____________________________________________ .

4. Тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү үткәрү урыны _____ ______________________________________________________________________

5. Планлы тикшерү үткәрү турында күрсәтмә: «___»________ , 20__ № ____.

6. Планлы тикшерү уздыручының (уздыручыларның) вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме: __________________________________________________

7. Тикшерүнең исәп номеры һәм тикшерүләрнең бердәм реестрында исәпкә алу номерын бирү датасы: ______________________________________________________________________

8. Мәҗбүри таләпләрнең әчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге:

| N п/п | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге | Мәҗбүри таләпләр куелган структур берәмлекләрне күрсәтеп, норматив хокукый актларны реквизитлары | Сорауларга җавап | | | искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | Таләпләр таралмый | |
| 1 | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | Автомобиль юлының бүленгән полосасы чикләрендә юл сервисы объектларын территорияне планлаштыру документлары һәм техник регламентлар таләпләренә туры киләме? | "Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2007 елның 08 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 1 өлеше (алга таба - Федераль закон) | | | | |
| 2 | Региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының бүленгән полосасы һәм юл буе полосалары чикләрендә урнаштырыла торган юл сервисы объектларын төзүгә, | Федераль законның 22 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләре | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | реконструкцияләүгә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында (алга таба - Шәһәр төзелеше кодексы) һәм Федераль законда билгеләнгән тәртиптә бирелгән рөхсәт бармы? | | | | | |
| 3 | Автомобиль юлы хуҗасының техник таләпләре һәм шартлары булган язма рәвештә автомобиль юлының юл буе полосалары чикләрендә капиталь төзелеш объектларын, юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектларны, юл сервисы объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә ризалык бармы? | Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлеше һәм 8 өлеше | | | | |
| 4 | Юл сервисы объектын автомобиль юлына кушу турында аның хуҗасы белән килешүләр бармы? | Федераль законның 22 статьясындагы 7 өлеше | | | | |
| 6 | Автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан бирелгән техник таләпләр һәм шартлар булган язма формада юл сервисы объектларының автомобиль юлына кушылган урыннарын реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны һәм ремонтлауны гамәлгә ашыруга ризалык бармы? | Федераль законның 22 статьясындагы 11 өлеше | | | | |
| 7 | Юл сервисы объектларының автомобиль юлына кушылган урыннарын реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны һәм ремонтлауны гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан бирелгән техник таләпләр һәм шартлар үтәләме? | Федераль законның 22 статьясындагы 11 өлеше | | | | |
| 8 | Юл сервисы объектлары транспорт чаралары тукталышы һәм туктап тору урыннары, шулай ук автомобиль юлыннан керү мөмкинлеген тәэмин итә торган керү, чыгу һәм кушылган урыннар белән, автомобиль юлы хуҗасы биргән техник таләпләр һәм шартлар нигезендә җиһазландырылганмы? | Федераль законның 22 статьясындагы 6 өлеше | | | | |
| 9 | Автомобиль юлына аркылы чыгу юлларына килеп туктаганда чыгу юллары, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында автомобиль юлын төзекләндерү элементлары белән җиһазландырылганмы? | Федераль законның 22 статьясындагы 6 өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Автомобиль юллары хуҗасы белән инженерлык коммуникацияләре хуҗасы төзегән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салуга, күчерүгә яисә яңадан урнаштыруга техник таләпләр һәм шартлар булган шартнамә бармы? | Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлеше | | | | |
| 11 | Әгәр мондый рөхсәт автомобиль юлының бүленгән полосасы чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салганда, күчергәндә яисә яңадан урнаштырганда кирәк булса, Шәһәр төзелеше кодексы һәм Федераль закон нигезендә бирелгән инженерлык коммуникацияләрен төзүгә рөхсәт бармы? | Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлеше | | | | |
| 12 | Автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан язма рәвештә бирелгән автомобиль юлының юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салуга, күчерүгә яисә яңадан урнаштыруга техник таләпләре һәм шартлары булган ризалык бармы? | Федераль законның 19 статьясындагы 3 өлеше | | | | |
| 13 | Автомобиль юлының юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салганда, күчергәндә яисә яңадан урнаштырганда Шәһәр төзелеше кодексы һәм Федераль закон нигезендә бирелгән инженерлык коммуникацияләрен төзүгә рөхсәт бармы? | Федераль законның 19 статьясындагы 3 өлеше | | | | |
| 14 | Автомобиль юлының бүленгән полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә аларны салганда, күчергәндә, яңадан төзегәндә инженерлык коммуникацияләре хуҗасы тарафыннан техник таләпләр һәм шартлар үтәлгәнме? | Федераль законның 19 статьясындагы 2 һәм 3 өлеше | | | | |
| 15 | Автомобиль юлының хуҗасы тарафыннан язма рәвештә бирелгән полосалар чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен планлаштырып урнаштыруны (инженерлык коммуникацияләрен проектлаганда, күчергәндә яисә яңадан урнаштырганда) килештерү бармы? | Федераль законның 19 статьясындагы 2.1 өлеше | | | | |

"___" _____________, 20__ ел
(тикшерү кәгазен тутыру
датасы күрсәтелә)

________________________ ____________ ___________________________

(тикшерү кәгазен тутыручы, затның вазыйфасы) (имза) (тикшерү кәгазен тутыручы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса)